| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САЛАУШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САЛАГЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.08.2021 с. Салауши № 24

2020 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлегендә салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 31 мартындагы 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 174 статьясы, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Салым чыгымнары исемлеге турында» 2021 елның 02 апрелендәге 05-13/2202 номерлы хатын үтәү максатында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «2020 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлегендә салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 31 мартындагы 6 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар исемендә «2020 елда» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. Карарга кушымта исемендә «2020 елда» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.3. Карарның 1 пунктында «2020 елда» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.4. Карарның 2 пунктында «2020 елда» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru)

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2021 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкчесе М.М. Мухамадиев